**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5833**
**26.10.2022**

«Яшьләр сәламәт яшәү рәвеше өчен»
шәһәр акциясен үткәрү турында

Яр Чаллы шәһәре халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау һәм наркотизацияләүне профилактикалау эшен оештыру максатларында, Башкарма комитетның «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәрендә халыкны наркотизацияләүне профилактикалау» муниципаль программасы турында» 2019 елның 30 октябрендәге 5595 номерлы карарын тормышка ашыру йөзеннән, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсенә «Яшьләр сәламәт яшәү рәвеше өчен» шәһәр акциясен 2022 елның 24 октябреннән 24 ноябренә кадәр үткәрергә.

2. Расларга:

1) «Яшьләр сәламәт яшәү рәвеше өчен» шәһәр акциясен үткәрү турында нигезләмәне 1 нче кушымтада каралганча;

2) «Яшьләр сәламәт яшәү рәвеше өчен» шәһәр акциясен үткәрү буенча оештыру комитеты составын 2 нче кушымтада каралганча.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 26 октябрендәге
5833 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Яшьләр сәламәт яшәү рәвеше өчен»
шәһәр акциясен үткәрү турында
нигезләмә

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «Яшьләр сәламәт яшәү рәвеше өчен» шәһәр акциясе (алга таба – акция) яшьләр тарафыннан наркотик чаралар куллануны кисәтү, яшьләрдә тормышның уңай кыйммәтләрен, үз-үзеңне тотуның һәм шәхси ресурсларның югары функцияле стратегияләрен формалаштыруга юнәлдерелгән комплекслы профилактик чараларны гамәлгә ашыру максатыннан үткәрелә.

2. Әлеге Нигезләмә пунктлары белән каралган чараларны Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның район хакимиятләре гамәлгә ашыра.

## 2 бүлек. Акциянең формалары һәм чаралары

3. Акция түбәндәге формаларда башкарыла:

1) Интернет, кәрәзле телефон һәм ышаныч телефоны аша наркотикларның таралу урыннары турында мәгълүмат тапшыру юлы белән гражданнарны профилактик активлыкка тарту;

2) шәһәр оешмаларында профилактик программаларны гамәлгә кертү;

3) яшүсмерләр һәм яшьләр өчен психологик семинарлар, интерактив чаралар;

4) наркомания проблемалары буенча ата-аналар лекторийләре;

5) иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре белән очрашулар;

6) яшүсмерләр һәм яшьләр өчен профилактик интерактив видеолекцияләр, дәресләр, уеннар, тренинглар;

7) тематик фестивальләр, күргәзмәләр, ток-шоулар, матбугат конференцияләре;

8) спорт ярышлары, спартакиадалар, уеннар.

4. Акция кысаларында түбәндәге чаралар үткәрелә:

1) массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмати-реклама чаралары:

- белгечләрнең аналитик мәкаләләре;
- әлеге тематика буенча белгечләрнең рекомендацияләре һәм консультацияләре;
- шәһәр халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау буенча җирле үзидарә органнарының, коммерцияле булмаган иҗтимагый оешмаларның эшчәнлеген яктырту;

- сәламәтлек саклау мәсьәләләре буенча балигъ булмаганнар арасында мәгълүмати-агарту эше;

- мәгариф оешмаларының наркоманияне профилактикалау эшчәнлеге турында мәгълүмат тарату;

- балаларны, яшүсмерләрне һәм яшьләрне массакүләм спорт һәм ял эшчәнлегенә җәлеп итү;

-- белгечләрне (шәһәрнең Мактаулы гражданнарын, педагогларны, психологларны, социологларны, медицина хезмәткәрләрен, балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчә инспекторларын, шәһәрнең иҗтимагый оешмалары вәкилләрен, дин әһелләрен) наркотизацияләү проблемалары буенча яшьләр телерадиопрограммаларында катнашуга җәлеп итү;

- массакүләм мәгълүмат чаралары өчен тематик материаллар тәкъдим итү;

- халыкның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту проблемалары буенча мәгълүмати буклетлар, аудио- һәм видеопродукцияләр, социаль реклама тарату;

2) яшәү урыны буенча:

- спорт ярышлары уздыру;

- массакүләм мәдәни чаралар уздыру;

- гаилә ялын оештырырга ярдәм итү;

- «хәвеф төркеме» яшүсмерләре җыела торган урыннарда профилактик рейдлар үткәрү;

3) консультация-укыту:

- гаилә консультациясе;

- мәгълүмат линияләренең эше;

- белем бирү оешмаларында, яшьләр сәясәте оешмаларында психологик ярдәм консультация пунктлары эше;

- наркотикларга бәйлелектән терелеп килүчеләрне реабилитацияләү, бәйлелектәгеләргә консультацияләр бирү буенча үзара ярдәм төркемнәре;

- сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау буенча иреклелеләр хәрәкәтләре оештыру һәм аларның эше.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева